**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**28.12.2021** **№ 1061**

# Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында Гаиләдә белем алу һәм үзлегеңнән белем алу турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 04 сентябрендәге 1486 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Мәгариф министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары - башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2021 елның 22 мартындагы 115 номерлы боерыгы нигезендә (алга таба - Тәртип), Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында Гаиләдә белем алу һәм үзлегеңнән белем алу турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 04 сентябрендәге 1486 номерлы карарының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1) «Гомуми нигезләмәләр» дип аталган I бүлекнең 1.8. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«1.8. Балигъ булган укучы яисә балигъ булмаган укучының ата-аналары (законлы вәкилләре) гаиләдә белем алуга күчү белән бәйле рәвештә гомуми белем бирү оешмасыннан укучыны чыгару турында боерык чыгарылган вакыттан алып 15 календарь көн эчендә яисә гаиләдә белем алуга күчү планлаштырыла торган уку елы башланганчы 15 календарь көннән ким булмаган вакыт эчендә гаиләдә белем алу/ үзлегеңнән белем алу формасында гомуми белем алу формасын сайлау турында, 2 нче кушымта нигезендә хәбәрнамә юллап, укучы яшәгән территориянең район мәгариф бүлегенә мәгълүмат җиткерәләр».

«2.5. Белем алучыны мәгариф оешмасына арадаш һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен экстерн белән кабул итү гражданнарны мәгариф оешмаларына кабул итү өчен гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла (Россия Мәгариф министрлыгының төп гомуми белем бирү программалары - башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2021 елның 22 мартындагы 115 номерлы боерыгында)

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - мәгариф бүлеге башлыгы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Хисамутдинов